Урта Комар авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«13» марта,2026 ел № 5

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2018 елның «27» апрелендәге 8 номерлы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге Советы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Урта Кумор авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Урта Кумор авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның «27» апрелендәге 8 номерлы Совет карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Урта Кумор авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) (2018 елның 07 ноябрендәге 27 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 10 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 11 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 5 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 14номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 4 номерлы, 2023 елның 31октябрендәге 30 номерлы, 2023 елның 18 декабрендәге 35 номерлы, 2024 елның 06 февралендәге 3 номерлы, 2024 елның 21 маендагы 16 номерлы, 2024 елның 20 ноябрендәге 36 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 10 нчы бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру.

1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль хезмәткәрләр әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган белешмәләрне тапшыралар. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.

2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм формада «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының

аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда) каралган чыгымнар турында белешмәләр тапшырырга тиеш.

3. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль законнар тарафыннан дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр була.

5. Муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрдән муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының түләү сәләтен билгеләү яисә ачыклау өчен, дини яисә башка иҗтимагый берләшмәләр, башка оешмалар, шулай ук физик затлар фондларына турыдан-туры яисә читләтелгән рәвештә иганәләр (взнослар) җыю өчен файдалану рөхсәт ителми.

6. Әлеге статья нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне ачуда яисә әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда куллануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

7. Муниципаль хезмәткәрнең «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда каралган чыгымнар хакында белешмәләрне тапшырмавы, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса, йә белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыруы, Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

8. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан әлеге әлеге бүлекнең 7 пунктында күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

9. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәткә кергәндә гражданнар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы чикләүләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен, аларның «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән бурычларын үтәвен

тикшерү Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

10. Банк, салым яисә закон белән саклана торган башка сер булып торучы белешмәләр бирү турындагы соратулар, тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнарга, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләргә, мондый гражданнарның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларына карата оператив-эзләү чаралары үткәрү турында хокук саклау органнарына соратулар муниципаль органнар мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) тарафыннан җибәрелә.

11. Контракт буенча җирлек башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә тапшыра.

12. Әлеге бүлекнең 11 пункты нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) карары белән Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

13. Әлеге бүлекнең 12 пункты нигезендә башкарылган тикшерү нәтиҗәсендә контракт буенча җирлек башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүче затның чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, әлеге Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) контракт буенча җирлек башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә аңа карата башка дисциплинар түләтүне куллану турында гариза белән җирле үзидарәнең тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле органына яисә судка мөрәҗәгать итә.»;»

1.2. 12 бүлекнең 1.3 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Кумор авыл җирлеге башлыгы С.В.Федоров

ОГРН 1021607752891 ИНН 1623001660